| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНОАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Лебедино **КАРАР**

**30.10.2020г.** **№2**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлегенең Лебедино авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 10 ноябренә 15 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлегенең Лебедино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Лебедино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту, вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
- техниканы – тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

- авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктырту (урам фонарьлары сатып алу, СИП үткәргеч сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

- җирлек территориясен төзекләндерү (парк зонасын коймалау өчен төзелеш материаллары, агачлар кисү, балалар мәйданчыгы элементларын алу, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);

- күмү урыннарын карап тоту (территорияне планлаштыру, мәгълүмати табличка, буяу, хуҗалык инвентаре сатып алу, керү юлларына вак таш җәю, контейнерлар сатып алып контейнер мәйданчыгын урнаштыру);

- янгынга каршы гидрантлар урнаштыру;

- чишмәне карап тоту (буяу һәм коймаларны ремонтлау);

- туган як музеен булдыру (витрин, өстәлләр, мәгълүмати күрсәткечләр, стендлар сатып алу;

- мәдәният һәм ялны оештыру өчен шартлар тудыру (музыка җиһазлары, өстәл уеннары, шахмат, шашка сатып алу.

ӘЙЕ ЮК».

2. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Лебедино авылы, Кооператив ур., 13А й.

Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Лебедино авылы, Кооператив ур., 3 йорт, Лебедино ав., Кооператив ур., 3А йорт, Лебедино авылы, Совет ур., 65А йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И. Тюкарев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ЛЕБЕДИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ